Personalia

DOI: 10.26907/2311-2042-2023-21-2-155-162

# AN EXAMPLE OF ENLIGHTENER

**Anis Foatovich Galimdjanov,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
anis_59@mail.ru.



**Vagiz Fatkhullovich Fatkhullin** (1937–2005) was a researcher in the field of structural mechanics, candidate of technical sciences (1973), Honored Worker of Science and Technology of the Republic of Tatarstan (1996).

In 1964, he graduated from the Kazan Institute of Civil Engineering (now Kazan University of Architecture and Civil Engineering) and began his teaching and scientific career at his home university. He was

**Вәгыйз Шәйхулла улы Фәтхуллин** (1937–2005) – төзелеш механикасы өлкәсендә галим, техник фәннәр кандидаты (1973), ТРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе (1996). Казан инженерлык-төзелеш институтын (хәзерге Казан архитектура-төзелеш университеты) тәмамлаган (1964). Педагогик һәм фәнни карьерасын үзе укыган югары уку йортында башлый. Төзелеш факультеты

**Вагиз Фатхуллович Фатхуллин** (1937–2005) – ученый в области строительной механики, кандидат технических наук (1973), заслуженный деятель науки и техники РТ (1996).

Выпускник Казанского инженерно-строительного института (ныне Казанский архитектурно-строительный университет) (1964).

Старт в педагогической и научной карьере сделал в родном

the Dean of the Faculty of Civil Engineering (1984–2005) and a professor in the Department of Reinforced Concrete Structures (1994–2005), with a break in 1980–1983.

He taught at the University of Annaba (Algeria).

деканы (1984–2005), тимер-бетон конструкцияләр кафедрасы профессоры (1994–2005), 1980–1983 елларда Аннаба шәһәре университетында (Алжир) укыта.

вузе. Декан строительного факультета (1984–2005), профессор кафедры железобетонных конструкций (1994–2005). В 1980–1983 гг. преподавал в университете города Аннаба (Алжир).

Most of the major work on the revival and development of the Tatar language begins, of course, with the "Declaration of State Sovereignty of the Tatar SSR", adopted on August 30, 1990. In the autumn of the same year, the Dean of the Construction Faculty of the Kazan Civil Engineering Institute, Vagiz Fatkhullin, having gathered a group of Tatar teachers, said: "If we are planning to give the Tatar language the real status of a state language, we must conduct pre-school education, secondary education and university courses in the mother tongue. It must be emphasized that if today our generation does not complete the main part of this noble task, in the coming years it will not be possible to create a unified system of Tatar education" [1, p. 36].

Vagiz Fatkhullin's idea was realized only in 1990 when the University began teaching builders in the Tatar language. It was based on the changes that took place in the country restoring its sovereignty and the national education system. There was also a social basis for this enterprise: it turned out that 55% of the students were Tatars and there was a team of highly qualified faculty members who could teach various subjects in the Tatar language.

In 1991, the main directions of the work were determined, courses in the Tatar language and terminology were launched, and a commission on methods and terminology was created. The leader, the Dean of the Faculty of Civil Engineering, Vagiz Fatkhullin, found many supporters. First of all, these were Associate Professors A. Narbekov and R. Shakirzyanov.

If we look at the life path of this outstanding personality who opened a new direction in the field of Tatar education – Tatar technical education in universities, we will see that he always strived for novelty and knowledge.

Vagiz Shaikhullovich Fatkhullin was born in 1937 in the village of Masgutovo, the Aznakaevsky District. There, he went to a seven-year school, then Secondary School No. 1 in the city of Almetyevsk and studied at the Construction Department of the Oil Technical School in the city of Oktyabrsk, Bashkortostan. After two years in military service, he graduated from the Kazan Institute of Construction Engineers in 1964 and began teaching at the Department of Building Structures [2].

In 1973, in Leningrad, he presented his Ph.D. thesis on the study of the prefabricated reinforced monolithic structures. In 1979, Vagiz Fatkhullin was awarded the academic title of associate professor and in 1994 – professor. In 1980–1983, as a university teacher, he taught at the University of Annaba in Algeria. In 1984–2005, he was the dean of the Construction Faculty at the Institute of Civil Engineers (now Kazan State University of Architecture and Civil Engineering - KGASU).

During his time at KSASU, V. Fatkhullin was actively involved in research, academic, methodological, educational and organizational work. He was the author of more than 70 scientific and research-methodological works on the calculation and design of prefabricated monolithic reinforced concrete structures and ten textbooks [3]. For his research and teaching achievements, in 1994 he was awarded the academic title of professor.

Vagiz Fatkhullin's multifaceted and active work devoted to preserving and developing the Tatar language deserves special attention. Under his leadership, the "concept of higher education in the Tatar language" was created.

In particular, it contains the following lines:

"...the development of a national education system comes as a result of the transformation of Tatarstan into the spiritual centre of all Tatars in the world, the fact that the Tatar language has got the state language status and other historical changes. Every ethnos that wants to live as a nation, to preserve its language, culture and historical experience, passing them on from generation to generation and developing, must have a complete education system.

The concept of higher education in the Tatar language is aimed at creating a developed education system of the Tatar people, the creation of its final stage that is still missing – the National Higher School. It reflects the nation's desire for education and the need for modern education, takes into account modern views on higher education and world trends, based on the need to use the

Tatar language in all spheres of human activity, to raise the Tatar ethnic group to a civilized level, ensure its future, preserve and develop its culture in accordance with constitutional rights and human rights principles....

...The historical, material and cultural heritage of the Tatar people is an important part of world civilization, and the Tatar language is an ancient and original philosophical system. Tatarstan is the spiritual center of all Tatars in the world, the only resurgent state. Under these conditions, the fact that Tatar people lack a full-fledged education system, which includes Higher School, leads to a serious loss for all humanity, to the disappearance of the language and nation.

The creation of national higher school and the preparation of highly qualified professionals capable of teaching in their native language is the only way both to raise the Tatar language to a global level corresponding to its history and essence and in general to preserve our language. The time has come to make the Tatar language the state language not only in word, but also in truth, which includes the establishment of national higher school.

There are other reasons confirming the need and possibility of creating national higher school:

− a life-long education of a Tatar child; higher school in the Tatar language is necessary for a life-long education of a Tatar child;

− national education is necessary to protect language, culture, national identity, preserve and develop national, material and cultural heritage, disseminate objective and scientifically based information about these realities;

− the lack of higher education in the native language and the failure to teach sciences in the Tatar language weakens the language and separates it from science;

− there are national secondary Tatar schools, some experience has been gained in the field of higher education; therefore, the basis has been laid for the creation of national higher school;

− there are teachers who can teach various special sciences in the Tatar language, including exact sciences at a highly qualified scientific level;

− textbooks and teaching aids are being created;

− since ancient times, the Tatar people have been distinguished by their desire for knowledge, understanding, respect for scientists and reverence for books;

− youth, parents gravitate towards their native language, there are many people who want to get a higher education in their native language;

− currently the ideas of national unity, national solidarity are spreading and developing; the desire for spiritual liberation, a sense of pride in one’s state, one’s nation and loyalty to one’s language are being revived;

− so, it is necessary to take advantage of today’s historical conditions and support the extensive use of the national language...” [4]

The implementation of this concept began first under the guidance of V. Fatkhullin at the Faculty of Construction of KSASU for those majoring in Industrial and Civil Engineering.

The educational process began with the selection of excellent students for the first year; two groups (42 students) were formed from 78 applicants. After this, every year two groups of students were enrolled in the Construction Department.

Based on the opportunities that had opened up, the Construction Institute (previously called KSASU) aimed at training builders with tertiary education who were fluent in the two state languages of the Republic of Tatarstan (Tatar and Russian) in their professional activities. A new provision was introduced into the University Charter: teaching is conducted not only in Russian, but also in other languages”. Thus, teaching was conducted mainly in a bilingual form (in Tatar and Russian).

The Tatar groups had a certain order of training, which gradually changed: during the adaptation period (the first 2–3 years), students studied subjects in the Tatar language, they became familiar with Tatar and Russian terms, and in the 3$^{rd}$ -4$^{th}$ years they switched to Russian. The 5$^{th}$ year courses and final exams were conducted in Russian. Some students presented their diploma projects in the Tatar language.

In 1996, the first graduates with the Tatar language instruction left KSASU (17 people). In 2005, due to the dwindling number of students at the institute, only one group with the Tatar language instruction was enrolled. However, the Institute has prepared more than 400 builders with tertiary education who got a university education in the Tatar language. Four of them defended their Ph.D. theses.

Several years ago, the Tatar department closed due to a lack of applicants. But, starting with the 2023 academic year, it has resumed its work.

For his services in the field of science and higher education, V. Fatkhullin was awarded the honorary titles "Excellence in Higher Education of the USSR", "Honored Worker of Science and Technology of the Republic of Tatarstan" and "Honored Worker of Vocational Education of Russia".

Unfortunately, his life was tragically cut short on September 21, 2005. He was only a year and a half away from his 70th birthday...

He passed away, but he lives on in the memory of his friends, disciples and colleagues. In 2017, on his 80th birthday, an exhibition was organized at the KSASU Historical Museum. In 2006, a memorial plaque was installed in building No. 4 in his memory.

Fatkhullin Vagiz had many works written during his lifetime, but they were never published. His comments on the development of the Tatar language, expressed at that time, have not lost their relevance today. One of the most relevant issues is the one about Tatar intellectuals.

"When we talk about Tatar intellectuals, we usually mean experts in the humanities. Technical intellectuals seem to be out of it. Why? After all, professionals in technical sciences, doctors and lawyers were educated in Russian and conducted their work in Russian. There were, of course, certain attempts to overcome injustice. Kayum Nasyri published books and dictionaries related to industry in Tatar. And in the 1930s, Tatar groups were organized in technical educational institutions, lectures were given, practical classes were conducted, coursework and dissertations were presented in the Tatar language. After that period, due to the abolition of the Latin alphabet and the outbreak of war, this work was lost. Moreover, with the closure of Tatar schools and Tatar pedagogical colleges in the 60s, the teaching of mathematics, physics and chemistry in the Tatar language practically ceased to exist in humanitarian educational institutions.

Under these conditions, with the beginning of the revival in the 90s, there was a revival of teaching subjects in the Tatar language, including vocational education. We ourselves, at the University of Architecture and Civil Engineering, have been developing Tatar education for 15 years and have achieved certain results.

However, we are concerned with a number of questions: Can we, following this way only, in Russian conditions, develop the ranks of the Tatar technical intellectuals and raise their prestige? Are the ranks of the Tatar intellectuals growing? Do we have a strategy of the development in this direction? Can Tatar intellectuals become a united organized force? Will we have future perspectives if we consider only those professionals who can use their mother tongue at work to be Tatar intellectuals?

In Russian conditions, there is another way to educate and develop national intellectuals, and a part of Tatar intellectuals have followed this path. For example, the famous navigator of the 19th–20th centuries, Admiral Ishak Islamov, was educated in Russian, wrote his research works in Russian, and at the same time compiled a dictionary of words borrowed into the Russian language from Tatar. Consequently, the Admiral of the Russian Fleet Islamov still remained a Tatar intellectual.

I had to work in Algeria, where I taught in French for several years. The students studied in French, dealt with documents drawn up in French, but still remained Algerian Arabs, while the Tatar spirit of our intellectuals, as you know, is the size of a tiny pebble.

Apparently, our family lacks national education. In the conditions of globalization, in the conditions of Russia, it is impossible to educate the Tatar intellectual just by formally conducting lessons of the Tatar language in schools. And the nation that does not have a higher education, a national spirit and highly moral intellectuals has no future.

In order for us to have a future, it is necessary to know the current situation well, to correctly envision tomorrow, to create a strategy for the preservation, education and development of our intellectuals, a state program" (see: [5]).

**References**

1. *Opyt organizatsii vysshego tekhnicheskogo obrazovaniya na tatarskom yazyke* (1991–2016 gg.) (2017) [Experience in Conducting Higher Technical Education in the Tatar Language (1991–2016)]. Materialy mezhdunarodnoi nauchno-prakticheskoi konferentsii. 196 p. Kazan', KGASU. (In Russian)

2. *Vagiz Shaikhullovich Fatkhullin* [Vagiz Shaikhullovich Fatkhullin]. URL: https://tatarica.org/ru/razdely/nauka/personalii/fathullin-vagiz-shajhullovich (accessed:15.08.2023). (In Russian)

3. Fatkhullin, V. Sh. (1993). *Zhelezobetonnye konstruktsii: Ucheb. Posobie* [Reinforced Concrete Structures: A Textbook]. 119 p. Kazan', KISI. (In Russian)

4. Fatkhullin, V. Sh., Shakirzyanov, R. A., Narbekov, A. I. *"Kontseptsiya vysshego obrazovaniya na tatarskom yazyke"* (1999) ["The Conception of Higher Education in the Tatar Language"]. Kazan', kabinet tatarskogo yazyka. URL:

https://www.ksaba.ru/universitet/structure/uos/tat/?yscli d=lo3uhs5ko2932829623 (accessed:15.08.2023). (In Russian)

5. Narbekov, A. *Tatarskii prosvetitel'* [Tatar Educator]. Vydayushchiesya tatarskie uchenye: stat'i, vospominaniya. Pp. 402–405. Kazan', Tat. kit. izd. (In Russian)

# МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ҮРНӘГЕ

**Әнис Фоат улы Галимҗанов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
anis_59@mail.ru.

Татар телен яшәтү, үстерү буенча олы эшләрнең күбесе, әлбәттә, 1990 нчы елның 30 нчы августында кабул ителгән «Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турында Декларация»дән башланып китә. Шул ук елның көзендә Казан төзүче-инженерлар институтының төзелеш факультеты деканы Вагыйз Фәтхуллин бер төркем татар мөгаллимнәрен җыеп болай ди: «Татар теленә чып-чынлап дәүләт теле статусы бирергә уйлыйбыз икән, без мәктәпкәчә тәрбияне дә, урта белем бирүне дә, югары белемле белгечләр хәзерләүне дә ана телендә алып барырга тиешбез. Шунысын да ассызыклап әйтергә кирәк: шушы изге эшнең төп өлешен бүген безнең буын үтәп чыга алмаса, алдагы елларда бербөтен татар мәгариф системасын төзеп булмас» [1, 36 б.].

Вәгыйз Фәтхуллин җитәкчелегендә югары белемле төзүчеләрне татар телендә әзерләүне яңадан оештыру эшләре бары тик 1990 елда гына мөмкин булды. Алар илебездә үзгәрешләр башлануга, суверенитет һәм милли мәгариф системасын торгызу идеяләренә нигезләнде. Моның өчен социаль база да бар иде: студентлар контингентының 55%ы татарлар икәне, төрле фәннәрне татарча укыта алырлык югары квалификацияле укытучылар һәм галимнәр барлыгы ачыкланды.

1991 елда эшнең төп юнәлешләре билгеләнде, татар теле һәм терминология буенча курслар эшли башлады, методика һәм терминология комиссиясе оештырылды. Эшне оештыручы лидерга – төзелеш факультеты деканы Вагыйз Фәтхуллинга күп ярдәмчеләр табылды. Беренче чиратта, алар доцентлар А.И. Нарбеков һәм Р.Ә. Шакирҗанов иде.

Татар мәгарифе өлкәсендә яңа юнәлеш – югары уку йортларында татарча техник белем бирүне ачып җибәргән бу олы шәхеснең тормыш юлына күз салсак, аның гел яңалыкка, белемгә омтылганын күрергә була.

Вагыйз Шәйхулла улы Фәтхуллин 1937 елда Азнакай районы Мәсгут авылында туа. Шунда җидееллык мәктәпне, аннан соң Әлмәт шәһәренең 1 нче урта мәктәбен тәмамлагач, Башкортстанның Октябрьский шәһәрендәге нефть техникумының төзелеш бүлегендә укый. Ике ел хәрби хезмәттә булып кайткач, 1964 елда Казан төзелеш инженерлары институтын тәмамлый һәм төзелеш конструкцияләре кафедрасында укыта башлый [2].

1973 елда Ленинградта җыелма-монолит конструкцияләрнең ныклыгын өйрәнүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. 1979 елда Вагыйз Фәтхуллинга доцент, 1994 елда профессор дигән гыйльми дәрәҗәләр бирелә. 1980–1983 елларда, югары белемле мөгаллим буларак, Алжирның Аннаба университетында укыта. 1984–2005 елларда – төзүче инженерлар институтының (хәзер Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты − КДАТУ) төзелеш факультеты деканы була.

КДАТУда эшләү дәверендә В. Фәтхуллин актив рәвештә фәнни-тикшеренү, фәнни-методик һәм укытуны оештыру эшләре белән шөгыльләнә. Аның җыелма-монолит тимер-бетон конструкцияләрне хисаплау һәм проектлау буенча 70тән артык фәнни һәм фәнни-методик хезмәте, 10 уку кулланмасы бар [3]. Зур фәнни һәм укыту өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа 1994 нче елда профессор дәрәҗәсе бирелә.

Вагыйз Шәйхулла улының татар телен саклау һәм үстерү буенча алып барган күпкырлы һәм актив эшчәнлеге аеруча игътибарга лаек. Аның җитәкчелегендә «Татар телендә югары белем бирү концепциясе» төзелә.

Аерым алганда, анда түбәндәге юллар бар:

«...Татарстан җир йөзендәге барлык татарларның рухи мәркәзе булып әверелү, анда татар теле дәүләти статус алу һәм башка тарихи үзгәрешләр милли мәгариф системасын үстерүне таләп итәләр. Милләт буларак яшәргә, телен, мәдәниятен, тарихи тәҗрибәсен югалтмаска, аларны буыннан буынга тапшырырга һәм үстерергә теләгән һәр халыкның тулы мәгариф системасы булырга тиеш.

Татар телендә югары белем бирү концепциясе татар халкының тулы мәгариф системасын булдыруга, аның әлегә җитешмәгән соңгы буынын – милли югары мәктәпне төзүгә һәм үстерүгә юнәлтелгән. Ул милләтнең белем эстәүгә омтылышын һәм заманча белемгә ихтыяҗын чагылдыра, югары белемгә булган заманча карашларны һәм дөньякүләм тенденцияләрне исәпкә ала, татар этносын цивилизацияле дәрәҗәгә күтәрү, аның киләчәген тәэмин итү, мәдәниятен саклау һәм үстерү өчен татар телен кеше эшчәнлегенең һәр өлкәсендә куллану зарурлыгына таяна, конституцион хокукларга һәм кеше хокукларын саклау принципларына нигезләнә...

...Татар халкының гакли, матди һәм мәдәни мирасы дөнья цивилизациясенең мөһим бер өлеше, ә татар теле – бик борынгы һәм үзенчәлекле фәлсәфи система. Татарстан – җир йөзендәге барлык татарларның рухи мәркәзе, яңа тернәкләнеп килүче бердәнбер дәүләте. Бу шартларда татар халкының югары мәктәпне дә эченә алган тулы мәгариф системасы булмау – кешелек дөньясы өчен җитди югалтуга – телнең һәм милләтнең юкка чыгуына илтә.

Милли югары мәктәпне булдыру һәм анда ана телендә эш алып барырлык югары квалификацияле белгечләр әзерләү – татар телен аның тарихына һәм асылына туры килгән дөнья югарылыгына күтәрү өчен генә түгел, ә гомумән, телебезне саклап калу өчен бердәнбер юл. Татар телен декларациядә генә түгел, чынбарлыкта да дәүләт теле итәргә, шул исәптән милли югары мәктәпне дә рәсмиләштерергә вакыт җитте.

Милли югары мәктәпне төзүнең кирәклеген һәм мөмкинлеген раслаган башка сәбәпләр дә бар:

– татар баласы өзлексез белем ала алсын өчен татар телендә эшләүче югары мәктәп кирәк;

– милли мәгариф телне, мәдәниятне, милли үзенчәлекләрне яклау, милләтнең гакли, матди һәм мәдәни мирасын саклау һәм үстерү, алар хакында объектив һәм фәнни нигезләнгән мәгълүмат тарату өчен кирәк;

– ана телендә югары белем бирмәү, төгәл фәннәрне татарча укытмау телне зәгыйфьләндерә, фәннән аера;

– татар телендә белем бирә торган милли урта мәктәп бар, югары белем бирүдә дә берникадәр тәҗрибә тупланды; димәк, милли югары мәктәпне төзү өчен нигез салынган;

– төрле махсус, шул исәптән төгәл фәннәрне югары гыйльми дәрәҗәдә татарча укытырлык һәм теләүче мөгаллимнәр бар;

– дәреслекләр, уку-укыту кулланмалары һәм әсбаплары булдырыла;

– татар халкы борынгыдан белемгә, гыйлем эстәүгә омтылуы, укымышлыларны ихтирам итүе, китапны хөрмәт итүе белән аерылып тора;

– яшьләр, ата-аналар туган телгә тартыла, ана телендә югары белем алырга теләүчеләр шактый; киләчәктә, татар мәктәп-гимназияләрен тәмамлаучылар күбәйгән саен, аларның саны арта барачак;

– хәзерге чорда милли бердәмлек, милли теләктәшлек идеяләре тарала һәм үсә, рухи азатлыкка омтылу, үз дәүләтең, үз милләтең, үз телең белән горурлану, аңа тугрылыклы булу хисләре яңара;

– милли тел эшләп торсын өчен бүгенге тарихи шартлардан файдаланырга, аларны булдырырга кирәк...» [4].

Шушы Концепцияне эшкә ашыру да башта В. Фәтхуллин җитәкчелегендә КДАТУның төзелеш факультетында сәнәгать һәм гражданлык төзелеше белгечлеге буенча башланды.

Уку процессы яхшы укыган укучыларны беренче курска сайлап алудан башланды, гариза биргән 78 абитуриент арасыннан ике төркем (42 студент) сайлап алынды. Шуннан соң ел саен төзелеш факультетына 2 төркем студент алына башланды.

Булган мөмкинлекләрне исәпкә алып, Төзелеш институтында (КДАТУ элек шулай дип атала иде) Татарстан Республикасының ике дәүләт телен (татар һәм рус телләрен) һөнәри эшчәнлектә иркен кулланырлык югары белемле төзүчеләр әзерләү максат итеп куелды. Уставка «укыту рус теленнән тыш, башка телләрдә дә алып барыла» дигән яңа нигезләмә кертелде. Шуңа таянып, укыту, нигездә, билингваль формада (татар һәм рус телләрендә) бара башлады.

Тора-бара татар төркемнәрендә уку тәртибе үзгәртелде: адаптация чорында (баштагы 2-3

елда) студентлар фәннәрне татар телендә укыйлар, татарча һәм русча терминнар белән танышалар, ә 3-4 курсларда русча укуга күчәләр. 5 нче курста уку, дәүләт имтиханнарын тапшыру рус телендә бара. Кайбер студентлар диплом проектларын татар телендә дә якладылар.

1996 елда КДАТУда татарча укучыларның беренче чыгарылышы (17 кеше) булды. 2005 елда, институтта студентлар контингенты кыскартылгач, татарча укытыла торган бер төркем генә туплана башлады. Шуңа да карамастан, татар телендә укыган 400дән артык югары белемле төзүчеләр әзерләнде. Аларны дүртесе кандидатлык диссертацияләрен якладылар.

Моннан берничә ел элек татар бүлеге абитуриентлар булмау сәбәпле ябылып торды. Ләкин 2023 нче уку елыннан башлап, бу бүлек үзенең эшен дәвам иттерде.

Фән һәм югары белем өлкәсендәге хезмәтләре өчен В.Ш. Фәтхуллинга «СССР югары белем отличнигы», «ТРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе», «Россиянең мактаулы профессиональ белем бирү хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Кызганычка каршы, аның гомере 2005 нче елның 21 нче сентябрендә фаҗигале өзелде. 70 яшькә җитәргә аңа нибары ел ярым калган иде...

Ул безнең арадан китсә дә, үзенең көрәштәшләре, укыткан студентлары, хезмәттәшләре хәтерендә яши. 2017 нче елда, аның 80 еллыгына багышлап, КДАТУ тарихы музеенда күргәзмә оештырылды. 2006 нчы елны 4 нче корпуста аның истәлегенә мемориаль такта куелды.

Фәтхуллин Вагыйз Шәйхулла улының үзе исән чагында язылып та, басылмый калган хезмәтләре күп. Аның татар телен яшәтү, үстерү буенча ул вакытта әйтелгән фикерләре бүген дә актуальлеген югалтмады. Шуларның иң актуальләреннән берсе – татар интеллигенциясе турында.

«Татар интеллигенциясе турында сүз алып барганда, гел генә диярлек гуманитар фәннәр белгечләрен истә тоталар. Техник интеллигенция болар рәтенә кертелми. Ни өчен? Чөнки техник фәннәр буенча белгечләр, табиблар, юристлар – белемне дә рус телендә алганнар, эшләрен дә рус телендә алып баралар. Талпынулар булган, әлбәттә. Каюм бабабыз да сәнәгатькә бәйле китаплар, сүзлекләр чыгарган. Узган гасырның 30 нчы елларында да техник уку йортларында татар төркемнәре оештырып, туган телебездә лекцияләр укыганнар, гамәли дәресләр алып барганнар, курс һәм диплом эшләре яклаганнар. Аннан соң, латинча имлябыз бетерелү, сугыш башлану сәбәпле, бу эш юкка чыккан. Алай гына түгел, 60 нчы елларда татар мәктәпләре, татар педагогия училищелары ябыла башлагач, гуманитар уку йортларында да математика, физика, химия фәннәрен татарча укыту бетте дисәк тә була.

Шушы шартларда 90 нчы елларда яңарыш башлангач, татарча укыту, шул исәптән татар телендә һөнәри белем бирү җанланып китте. Үзебез дә архитектура-төзелеш университетында 15 ел буена татарча укытуны үстереп, ниндидер уңышларга ирештек.

Шулай да безне берничә сорау борчый да борчый: бу юл белән генә Россия шартларында татар техник интеллигенциясенең сафларын үстерә, аның абруен күтәрә алырбызмы? Гомумән, татар интеллигенциясенең сафлары артамы? Бу юнәлештә безнең стратегиябез бармы? Татар интеллигенциясе бер оешкан көч булдымы, була аламы? Туган телебездә эш алып барырлык белгечләребезне генә татар интеллигенциясе дип санасак, безнең киләчәгебез булырмы?

Россия шартларында милли интеллигенцияне тәрбияләү, үстерүнең икенче юлы да бар, һәм татар җанлы шәхесләребезнең бер өлеше шул юлдан барган да. Мәсәлән, XIX-XX гасырларда яшәгән мәшһүр диңгезчелек фәне белгече, адмирал Исхак Исламов рус телендә белем ала, фәнни хезмәтләрен рус телендә яза, шул ук вакытта рус теленә татар теленнән кергән сүзләр лөгатьлеге төзи. Димәк, рус флоты адмиралы Исламов барыбер татар интеллигенты булып кала.

Миңа Алжирда берничә ел француз телендә укытып кайтырга туры килде. Француз телендә белем алалар, французча төзелгән документлар белән эш алып баралар, ә барыбер алжирлы гарәп булып калалар. Ә безнең укымышлыларыбызның күбесе – үзегез беләсез инде, татарлыклары ташка үлчим генә.

Безнең гаиләдә милли тәрбия җитми, күрәсең. Мәктәпләрдә формаль рәвештә татар теле дәресләре үткәреп кенә, глобальләшү чорында, Россия шартларында, татар интеллигенциясен тәрбияләп булмастыр. Ә югары белемле, милли җанлы, әхлаклы интеллигенциясе булмаган халыкның киләчәге дә юктыр.

Киләчәгебез булсын өчен бүгенге хәлебезне яхшы белеп, иртәгәбезне дөрес күзаллап, интеллигенциябезне саклау, тәрбияләү, үстерү стратегиясен, дәүләт программасын булдыру зарур» (Кар.: [5]).

**Әдәбият**

1. Татар телендә югары техник белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар) / Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан: КДАТУ, 2017. 196 б.

2. Вагыйз Шәйхулла улы Фәтхуллин // https://tatarica.org/ru/razdely/nauka/personalii/fathullin-vagiz-shajhullovich (мөрәҗәгать итү вакыты 15.08.2023)

3. *Фатхуллин В. Ш.* Железобетонные конструкции: учеб. пособие. Казань: КИСИ, 1993. 119 с.

4. *Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә., Нарбеков А.*И «Татар телендә югары белем бирү концепциясе» (Казан, 1999) // Татар теле кабинеты // https://www.ksaba.ru/universitet/structure/uos/tat/?yscl id=lo3uhs5ko2932829623. (мөрәҗәгать итү вакыты 15.08.2023)

5. *Нарбеков А.* Татар мәгърифәтчесе // Мәшһүр татар галимнәре: мәкаләләр, истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 402–405 б.